**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 14 июнендәге 2478 номерлы карары**

**Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар, торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен Казан шәһәренең торак фондында торак урыннарны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын билгеләү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2018 елның 6 апрелендәге 213/пр номерлы «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар, торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү, шулай ук мондый түләү күләмен үзгәртүнең чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү буенча методик тәкъдимнәрне раслау хакында» боерыгының 4.1 пунктына таянып, **карар бирәм**:

1. Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар, торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен Казан шәһәренең торак фондында торак урыннарны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын 2024 елның 1 июленнән 2025 елның 30 июненә кадәрге чорга 7,96% тигез итеп билгеләргә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында бастырып чыгарырга (www.docskzn.ru) һәм аны Казан шәһәре җирле үзидарә органнары рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**